| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БАГАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.04.2024ел. Багай ав. № 5

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советының 2023 елның 19 октябрендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 79 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 28.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 23 мартындагы 54-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советының 2023 елның 19 октябрендәге 14 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.5. пунктын түбәндәге эчтәлекле 13 пунктчасы белән тулыландырырга:

«13) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган, яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба - анкетада булган мәгълүмат), анкетада булган мәгълүматның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында хәбәр итәргә.».

1.2. 5.1. пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә һәм (яисә) аны узу чорында ялган документлар һәм (яисә) ялган белешмәләр кергәндә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлешен раслый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) ялган белешмәләрне тапшырганда йә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне,

тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында таныклый торган документларны һәм (яисә) белешмәләрне тапшырмау;».

1.3. 8.3. пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетаны;».

1.4. 8.4 пунктында «Белешмәләр» сүзеннән соң «(анкетадагы белешмәләрне исәпкә алмаганда)» сүзләрен өстәргә.

1.5. 17.1. пунктының 11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм муниципаль хезмәткәрләр аны узган чорда граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм уздыру;».

1.6. 17.2. пунктның 10 пунктчасында беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«максатчан уку турында шартнамә төзү конкурсында Россия Федерациясе дәүләт телен белгән, беренче тапкыр тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм уку яисә башка шартнамә буенча бурычлары булмаган, уку тәмамланганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган гражданнар катнашырга хокуклы.».

1.7. 21.6. пунктны түбәндәге эчтәлекле 21.6.15. пунктчасы белән тулыландырырга:

«21.6.15. Мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса, муниципаль хезмәткәр коррупциягә каршы көрәш максатларында әлеге Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтларын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.».

1.8. 23.5. пунктны түбәндәге эчтәлекле 23.5.1. пунктчасы белән тулыландырырга:

«23.5.1. Муниципаль хезмәткәрнең белә торып, 23.5. пунктында күрсәтелгән дөрес булмаган белешмәләр бирүе, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Багай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Багай авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Кузнецова